БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 01 2023 ел № 58

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр (вәкаләтләрнең бер өлешен) кабул итү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 155 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023 елның 01.02
58 номерлы карарына
1 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3429,55 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 967,30 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3396,63 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023 елның 01.02
68 номерлы карарына
2 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 295,36 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3134,19 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 967,30 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3396,63 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023 елның 01.02
58 номерлы карарына
3 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Т\б № | Муниципаль берәмлек, авыл җирлекләре исеме | Җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | Балтач шәһәр җирлеге | 7 793,48 |
| 2 | Борбаш авыл җирлеге | |
| 3 | Борнак авыл җирлеге | |
| 4 | Югары Субаш авыл җирлеге | |
| 5 | Карадуган авыл җирлеге | |
| 6 | Куныр авыл җирлеге | |
| 7 | Кече Лызи авыл җирлеге | |
| 8 | Норма авыл җирлеге | |
| 9 | Нөнәгәр авыл җирлеге | |
| 10 | Пыжмара авыл җирлеге | |
| 11 | Салавыч авыл җирлеге | |
| 12 | Смәел авыл җирлеге | |
| 13 | Сосна авыл җирлеге | |
| 14 | Урта Көшкәт авыл җирлеге | |
| 15 | Шеңшеңәр авыл җирлеге | |
| 16 | Шубан авыл җирлеге | |
| 17 | Чепья авыл җирлеге | |
| 18 | Яңгул авыл җирлеге | |